КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 30 май г.Казань № 440

Объектларны дезинфекцияләү һәм йогышлы авырулар чыганакларында, шул исәптән яңа коронавирус йогышлы авыруы барлыкка килү яки таралу өчен шартлар булган һәм саклана торган территорияләрдә һәм урыннарда башка санитария-эпидемиягә каршы чаралар үткәрү чараларын тормышка ашыру өчен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының резерв фонды акчасы исәбеннән Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Объектларны дезинфекцияләү һәм йогышлы авырулар чыганакларында, шул исәптән яңа коронавирус йогышлы авыруы барлыкка килү яки таралу өчен шартлар булган һәм саклана торган территорияләрдә һәм урыннарда башка санитария-эпидемиягә каршы чаралар үткәрү чараларын тормышка ашыру өчен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының резерв фонды акчасы исәбеннән Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны атарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Сәламәтлек саклау, спорт һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру мәсьәләләре идарәсенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2020 ел, 30 май, 440 нчы
карары белән расланды

Объектларны дезинфекцияләү һәм йогышлы авырулар чыганакларында, шул исәптән яңа коронавирус йогышлы авыруы барлыкка килү яки таралу өчен шартлар булган һәм саклана торган территорияләрдә һәм урыннарда башка санитария-эпидемиягә каршы чаралар үткәрү чараларын тормышка ашыру өчен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының резерв фонды акчасы исәбеннән Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибе

1. Бу Тәртип объектларны дезинфекцияләү һәм йогышлы авырулар чыганакларында, шул исәптән яңа коронавирус йогышлы авыруы барлыкка килү яки таралу өчен шартлар булган һәм саклана торган территорияләрдә һәм урыннарда башка санитария-эпидемиягә каршы чаралар үткәрү чараларын тормышка ашыру өчен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының резерв фонды акчасы исәбеннән Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар (алга таба – башка бюджетара трансфертлар) бирү механизмын билгели.

2. Башка бюджетара трансфертлар объектларны дезинфекцияләү һәм йогышлы авырулар чыганакларында, шул исәптән яңа коронавирус йогышлы авыруы барлыкка килү яки таралу өчен шартлар булган һәм саклана торган территорияләрдә һәм урыннарда башка санитария-эпидемиягә каршы чаралар үткәрү чараларын тормышка ашыру өчен Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына бирелә.

3. Бу Тәртип нигезендә бирелә торган бюджет акчасы белән баш эш итүче булып Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы (алга таба – Министрлык) тора.

4. Башка бюджетара трансфертларны алучы булып Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты тора.

5. Башка бюджетара трансфертлар 2020 елга, 2021 һәм 2022 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджетының җыелма бюджет исемлегендә каралган һәм бу Тәртипнең 2 нче пунктында күрсәтелгән максатлар өчен тиешле финанс елына Министрлыкка җиткерелгән бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бирелә.

6. Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына башка бюджетара трансфертларны бирү шартлары түбәндәгеләр була:

Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетында (Казан шәһәре бюджетының җыелма бюджет исемлегендә) муниципаль берәмлекнең финанслашу максатларында башка бюджетара трансфертлар бирелә торган чыгым йөкләмәләрен үтәүгә бюджет ассигнованиеләре аларны үтәргә кирәкле күләмдә булу;

Министрлык белән бу Тәртипнең 9 нчы пункты нигезендә башка бюджетара трансфертлар бирү турында килешү (алга таба – килешү) төзү.

7. Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитеты Министрлыкка бу Тәртипнең 2 нче пунктында күрсәтелгән чараларны тормышка ашыруга башка бюджетара трансфертлар бирү турында ирекле рәвештә язылган заявка кертә.

8. Башка бюджетара трансфертлар тиешле финанс елына Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$C = N + P + Q + R + L,$$

монда:

N – исәпләүләр белән хезмәт өчен түләү чыгымнары;

P – генераторлар, сиптергечләр сатып алу чыгымнары;

Q – бәйләү чаралары сатып алу чыгымнары;

R – дезинфекция чаралары, бер тапкыр кулланыла торган битлекләр, антисептиклар, юу һәм чистарту чаралары сатып алу чыгымнары;

L – ягулык-майлау материалларына түләү өчен.

Әлеге чыгымнар Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан расланган объектларны дезинфекцияләүгә һәм йогышлы авырулар чыганакларында, шул исәптән яңа коронавирус йогышлы авыруы барлыкка килү яки таралу өчен шартлар булган һәм саклана торган территорияләрдә һәм урыннарда башка санитария-эпидемиягә каршы чаралар үткәрүгә бәйле чараларны тормышка ашыруга чыгымнар сметасы нигезендә билгеләнә, аңа финанс-икътисадый нигезләмә теркәлә, әлеге нигезләмәдә, чыгымнарның күләмен нигезли торган мәгълүматны һәм аны алу чыганагын (бердәй (бертөрле) товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрнең базар бәяләре турында аналитик мәгълүмат, шул исәптән җитештерүче оешмаларның бәяләре турында, дәүләт статистикасы органнарында, шулай ук массакүләм мәгълүмат чараларында һәм махсус әдәбиятта (җитештерүчеләрнең һәм тәэмин итүчеләрнең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларын кертеп) булган бәяләр дәрәҗәсе турында мәгълүмат) күрсәтеп, чыгымнар юнәлешләре калькуляциясе бирелергә тиеш.

9. Башка бюджетара трансфертлар Министрлык һәм Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитеты арасында башка бюджетара трансфертлар бирү турында карар кабул ителгән көннән календарь көннәрдә исәпләнә торган 10 көн эчендә төзелә торган башка бюджетара трансфертлар бирү турындагы килешү нигезендә бирелә, анда түбәндәгеләр карала:

башка бюджетара трансфертларның максатчан билгеләнеше;

бирелә торган башка бюджетара трансфертларның күләме;

башка бюджетара трансфертларны күчерү вакытлары;

башка бюджетара трансфертлардан файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткечләре;

Казан шәһәре муниципаль берәмлеге тарафыннан башка бюджетара трансфертлардан максатчан файдалануны тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыру;

алучы тарафыннан финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып башка бюджетара трансфертлар торган чыгымнарны гамәлгә ашыру һәм башка бюджетара

трансфертлардан файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткечләрен үтәү турында хисаплылык бирү тәртибе, формасы һәм вакытлары;

бу Тәртиптә билгеләнгән шартлар бозылган очракта, килешүне өзү тәртибе;

якларның җаваплылыгы.

10. Килешүдә башка бюджетара трансфертлардан файдалану нәтиҗәлелегенең түбәндәге күрсәткечләре билгеләнә:

эшкәртелергә тиешле гомуми мәйданда йогышлы һәм паразитар авырулар чыганакларында эшкәртелгән мәйданның чагыштырма авырлыгы – 100 процент;

эшкәртелергә тиешле әйберләрнең гомуми авырлыгында дезинфекция камераларында эшкәртелгән әйберләрнең чагыштырма авырлыгы – 100 процент.

Башка бюджетара трансфертлардан файдалану нәтиҗәлелеген бәяләү килешүдә билгеләнгән башка бюджетара трансфертлардан файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткече мәгънәсен һәм агымдагы ел тәмамлану йомгаклары буенча фактта ирешелгән башка бюджетара трансфертлардан файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткече мәгънәсен чагыштыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

11. Башка бюджетара трансфертлар Министрлык тарафыннан Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына килешү төзелгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 7 көн эчендә Россия Федерациясе Үзәк банкы учреждениесендә муниципаль берәмлекләр бюджетлары акчасы белән операцияләрне исәпкә алу өчен ачылган Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсенең территориаль органы счетына күчерелә.

12. Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитеты Министрлыкка, хисап елыннан соң килә торган 10 нчы эш көненнән дә соңга калмыйча, бу Тәртипкә теркәлгән кушымтада бирелгән форма буенча Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетының финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып башка бюджетара трансфертлар торган чыгымнары турында һәм башка бюджетара трансфертлардан файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткечләрен үтәү турында хисап кертә.

13. Казан шәһәре муниципаль берәмлеге тарафыннан башка бюджетара трансфертлар биргән елның 31 декабре хәленә карата бу Тәртипнең 10 нчы пунктында каралган күрсәткеч мәгънәсенә ирешелмәгән очракта, башка бюджетара трансфертлар биргән елдан соң килә торган елның 1 мартына кадәр Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетыннан Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиешле акча күләме ($V_{кире\ кайтару}$) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$V_{кире\ кайтару} = V_{мбт} \times k \times 0{,}1,$$

монда:

$V_{мбт}$ – хисап финанс елында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге бюджетына бирелгән башка бюджетара трансфертлар күләме;

k – башка бюджетара трансфертларны кире кайтару коэффициенты.

14. Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетыннан Татарстан Республикасы бюджетына хисап финанс елында Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына бирелгән башка бюджетара трансфертлар күләмендә кире кайтарылырга тиешле акча күләмен ($V_{мбт}$) исәпләгәндә, башка бюджетара

трансфертлар биргән елдан соң килә торган елның 1 гыйнвары хәленә карата башка бюджетара трансфертларның файдаланылмый калган өлеше исәпкә алынмый.

15. Башка бюджетара трансфертларны кире кайтару коэффициенты (k) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$k = 1 - \frac{T}{S},$$

монда:

T – ел ахырына башка бюджетара трансфертлардан файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткеченең фактта ирешелгән мәгънәсе;

S – килешүдә билгеләнгән башка бюджетара трансфертлардан файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткеченең план буенча мәгънәсе.

16. Бу Тәртип нигезендә алынган, агымдагы финанс елының 1 гыйнвары хәленә карата файдаланылмаган башка бюджетара трансфертлар агымдагы финанс елының беренче 15 эш көне эчендә Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш.

Министрлыкның хисап финанс елында файдаланылмаган башка бюджетара трансфертларга ихтыяҗ булу турындагы карары нигезендә акча әлеге башка бюджетара трансфертларның калган өлешеннән артмаган күләмдә агымдагы финанс елында әлеге башка бюджетара трансфертлар бирү максатларына туры килә торган чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен Казан шәһәре бюджеты кеременә кире кайтарылырга мөмкин.

Әгәр дә бу Тәртип нигезендә алынган башка бюджетара трансфертларның файдаланылмый калган өлеше Татарстан Республикасы бюджеты кеременә күчерелмәгән булса, әлеге акча Татарстан Республикасы бюджеты кеременә, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән гомуми таләпләрне үтәп, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнә торган тәртиптә түләтелергә тиеш.

17. Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитеты тапшырыла торган хисап мәгълүматларының дөрес булмавы һәм башка бюджетара трансфертлардан максатчан файдаланмау өчен законнар нигезендә җавап бирә.

18. Башка бюджетара трансфертлардан максатчан файдалануны тикшерүдә тоту Министрлык һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан законнар нигезендә гамәлгә ашырыла.

Объектларны дезинфекцияләү һәм йогышлы авырулар чыганакларында, шул исәптән яңа коронавирус йогышлы авыруы барлыкка килү яки таралу өчен шартлар булган һәм саклана торган территорияләрдә һәм урыннарда башка санитария-эпидемиягә каршы чаралар үткәрү чараларын тормышка ашыру өчен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының резерв фонды акчасы исәбеннән Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенә кушымта

Форма

Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетының финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып башка бюджетара трансфертлар торган чыгымнары турында һәм башка бюджетара трансфертлардан файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткечләрен үтәү турында
хисап

Тапшыру вакыты: еллык.
Тутырыла: хисап елы башыннан алып арта бара торган йомгак белән.
Үлчәү берәмлеге: сум (өтердән соң икенче унарлы билгегә кадәр төгәл итеп).

1. 20 ___ елның «1» _____ е(ы) хәленә карата
финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып
башка бюджетара трансфертлар торган чыгымнар турында
мәгълүматлар

| Т/с | Хисап елы башына акчаның калган өлеше, барлыгы | Шул исәптән ихтыяҗ булуы расланган өлеше | Татарстан Республикасы бюджетыннан акча керде | Касса чыгымы | Үткән еллардагы акчаның файдаланылмый калган өлеше торгызылды | Үткән еллардагы акчаның файдаланылмый калган өлеше Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылды | Хисап елы ахырына акчаның калган өлеше |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
| | | | | | | | |

2. 20 ___ елның «1» _____ енә(ына) башка бюджетара трансфертлардан файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткечләрен үтәү турында мәгълүматлар

| Т/с | Күрсәткеч исеме | Күрсәткечнең план буенча мәгънәсе | Хисап датасы хәленә карата күрсәткечнең ирешелгән мәгънәсе | Планны үтәү проценты | Тайпылу сәбәбе |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| | | | | | |

Җитәкче _____________ __________/_________________________
(вәкаләтле зат) (вазыйфасы) (имзасы) (имзаны таркатып язу)

М.У.

Башкаручы _____________ __________/_________________________
(вазыйфасы) (имзасы) (имзаны таркатып язу)

__________________________________________